КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 август г.Казань № 697

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль юлларын төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында, җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез милек объектларын алу һәм автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Автомобиль юлларын төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында, җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез милек объектларын алу һәм автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка

бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2020 ел, 29 апрель, 350 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Автомобиль юлларын төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында, базар бәясен бәйсез бәяләү үткәрү һәм җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез милек объектларын алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Автомобиль юлларын төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында, базар бәясен бәйсез бәяләү үткәрү һәм җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез милек объектларын алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.»;

әлеге карар белән расланган Автомобиль юлларын төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында, җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез милек объектларын алу һәм автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль юлларын төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында, базар бәясен бәйсез бәяләү үткәрү һәм җир кишәрлекләрен, аларда урнашкан күчемсез милек объектларын алу, шулай ук автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплау өлешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе»;

1 пунктта:

«Казан ш. муниципаль берәмлеге" сүзләрен " Казан шәһәре муниципаль берәмлеге» сүзләренә алмаштырырга;

«өлешендә» сүзләренә кадәр «базар бәясен бәйсез бәяләү үткәрү" сүзләрен өстәргә;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Башка бюджетара трансфертлар әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга Министрлыкка җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.»;

5 пунктның дүртенче абзацында «бәясе» сүзеннән соң «базар бәясен бәйсез бәяләү уздыру" сүзләрен өстәргә;

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$O = P_1 + P_2 + P_3 + P_4,$$

монда:

O – муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертларның күләме турында;

$P_1$ – муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләренең һәм аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектларының базар бәясен бәйсез бәяләүне үткәрүгә бәйле чыгымнар күләме;

$P_2$ – автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен алу белән бәйле чыгымнар күләме;

$P_3$ – автомобиль юллары төзүгә бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрендә урнашкан күчемсез милек объектларын алуга бәйле чыгымнар күләме;

$P_4$– автомобиль юллары төзелеше белән бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләрен тартып алганда милекчеләргә китерелгән зыянны каплауга бәйле чыгымнар күләме.».

2. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин